**Байбулатова Л.**
**“Асар”ның сызып ташланган юллары**
**// Гасырлар авазы - Эхо веков, 2002, №1-2.**

Ризаэддин Фәхреддинов – XIX йөз ахыры-XX йөз башындагы катлаулы чорда яшәп, гомереңнең күп өлешен татар халкына хезмәт итүгә багышлаган дин эшлеклесе, тарихчы галим һәм педагог. Аның тарафыннан күп хезмәтләр язылган, шуларның күбесе үзе исән вакытта ук басылган һәм хәзер дә басылалар. Шулай да, әсәрләренең шактый өлеше әлегәчә кулъязма рәвешендә кала бирә. Мәсәлән, Россия фәннәр академиясенең Уфа гыйльми үзәге фәнни архивындагы Р.Фәхреддинов фондында 40 томлык кулъязма материал саклана, шуларның егерме дүртесен Р. Фәхреддинов үзе язган яки төзегән[1]. Кулъязмалар мөселманнарның Диния нәзарәтендә сакланганда ук, бу материал М. Госманов тарафыннан өлешчә тасвирланган иде[2]. Соңрак та кулъязма мирас галимнәр игътибарыннан читтә калмады[3].

Р. Фәхреддинов эшчәнлеге күпкырлы, шуларның берсе – тарих. Әсма Шәрәф-Фәхреддинованың искә алуынча, ул фәнни хезмәт белән чын-чынлап Уфадагы Диния нәзарәтендә казый вазифасын башкарганда шөгыльләнеп китә[4]. Анда ул архивтан файдалану мөмкинлеге ала һәм архив документларын билгеле бер тәртипкә китерә башлый. Бу документларның (Россия мөселманнары турында тарихи материаллар, татар һәм башкортларның меңләгән метрика кенәгәләре) әһәмиятен аңлап, ул киләчәк буыннарны мондый материалларга карата сакчыл булырга өнди[5]. Бигрәк тә Риза казый мөселманнарның архивы үз кулларында булырга тиешлегенә игътибарны юнәлтә[6]. Казанны алганда рус гаскәрләре ничек шул чорның кыйммәтле әсәрләрен юк иткән булсалар, мөселманнарның Дини идарә архивы руслар кулына эләккән очракта, татар халкы тарихы буенча документаль чыганакларның бай тупланмасы, мөгаен, шулай ук исән калмастыр. Мондый фикерләр тууга нигез барлыгына Р. Фәхреддинов тирәнтен борчыла.

Патша хакимияте чорындагы Россиядә татар китабын бастыру бик зур кыенлыкларга очрый. Ә. Кәримуллин әйтеп үткәнчә, татар китабына аның “инородецларныкы” булуы зыян китерә[7]. Хөкүмәт этник һәм сәяси үзаңны үстерә торган басмаларны тыярга тырыша. Татар халкын үз мәдәниятеннән ераклаштыру өчен цензорлар да күп көч куя. Цензор вазифасын төрек теле һәм әдәбияты белгече, профессор В.Д.Смирнов (1880-1905) үти башлагач, татар китабы тарихында бигрәк тә хәвефле чор башлана[8]. В.Д.Смирнов кандидатурасы самодержавиеның реакцион даирәләре өчен иң кулай була. Аңа хәтле кыска вакыт эчендә, рустан башка милләт кешеләренә мәрхәмәтле булулары сәбәпле, берничә цензор алышына. В. Д. Смирнов турында Н. Ильминский болай дип яза: “Ул – тырыш, эшен җиренә җиткереп башкаручы цензор. Мөселманнарга карата нейтраль мөнәсәбәттә. Шуңа күрә татарлар аңа ачулы” [9]. Смирновның замандашлары аның рус булмаган халыкларны милли рус бердәмлеген таркатучы сәбәпләрнең берсе дип санавын һәм аларга карата начар мөнәсәбәттә торуын таныйлар. Ул гадәттән тыш шовинист булган[10]. Ләкин, икенче яктан караганда, В. Д. Смирнов үз чорының “җимеше”. Псаломчы малае буларак, ул югары рухани белем ала. Рус бөеклеге идеясе аның аңына яшьтән үк сеңдерелә. Әмма, Россияне сакларга омтылып, ул татар халкына төзәтелмәслек зарар китергән. Эшчәнлегенең башында Смирнов бары тик дини эчтәлекле әсәрләрне тәнкыйтьләсә[11], XIX йөзнең 90 нчы елларыннан башлап, ул халыкка файдалы китапларга, яңа татар әдәбияты әсәрләренә, шулай ук рус һәм көнбатыш язучыларының хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итүгә каршы чыга[12]. Смирнов төзәтмәләреннән соң, татар авторларының күпчелек әсәрләренең эчтәлеге шул дәрәҗәдә ярлыланган ки, кайбер авторлар аларны бастырудан баш тартканнар. Мисал итеп, Гаяз Исхакыйның В. Д. Смирнов кулына эләккән “Ике йөз елдан соң инкыйраз”ын китерергә мөмкин. Беренче тапкыр бу әсәр 1904 елда кыскартулар белән басылган. Смирнов татар милләтен уята алырлык дип санаган иң “хәтәр” сүзләрне һәм җөмләләрне сызып ташлаган[13].

Мәшһүр татар галиме һәм фикер иясе Р. Фәхреддиновның күптомлы биобиблиографик характердагы “Асар” исемле хезмәте дә шундый ук язмышка дучар булган. Бу хезмәт 1917 елга хәтле татар историографиясенең феномены санала[14]. КДУ китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә “1496-т” шифры астында “Асар”ның I томының 1 нче җөзьэсе(-кисәге)нең төп кулъязма нөсхәсе саклана[15]. Ул А. Фәтхи тарафыннан кыскача тасвирлана[16].

Кулъязма 1899 елның сентябрендә – автор Уфада яшәгәндә – Петербургтагы цензурага җибәрелә[17]. Шул ук елның 20 сентябрендә цензура бу әсәрне бастыруга рөхсәт бирә. “Асар”ның беренче җөзьэсе 1900 елда Казан университетының типо-литографиясендә басыла. Ләкин инде бу киселгән-кыскартылган вариант була.

Кулъязманың төп нөсхәсендә беренче җөзьэнең мөкаддимәсе тугыз бүлектән торган. Ул тарихны фән буларак билгеләүдән башлана. Биредә тарих фәненең торышы, биографик характердагы хезмәтләр язу хакында мәсьәләләр күтәрелә. Татар халкы тарихы буенча чыганакларның аз саклануына авторның күңеле сыкрый. Кереш өлешендә хезмәтнең төп максатын да күрсәтә: *“Әдип вә галимнәре улмаган кавем бәхетсез. Мәшһүр кемсәләрне оныткан халык хәмиятсез[18], әдәбияты улмаган милләт рухсыз” дигән сүз хәтерләрдәдер. Ошбу сәбәп өчен, үз кавемемезнең мәгъруф[19] кемсәнәләрне җыеп тәгъриф итмәк[20] өчен ошбу китапны язарга ният иттем”* [21].

В. Д. Смирнов үз төзәтмәләрен икенче бүлектән кертә башлый. Казанның 1552 елның 2 октябрендә руслар тарафыннан алынуы турында сүз барган бишенче биттә җөмләнең *“Казан шәһәрендә бер мөселман калдырмай кылычтан үткәрелмеш”* дигән кисәге сызып ташланган. Ул чорда цензура хакындагы уставта мәкаләләрне бастыру турында: “...әгәр дә алар катлаулар арасында низаг китереп чыгаруга сәбәп булса, бастырып чыгарудан тыелалар” дигән положение булган[22]. Мөгаен, Смирнов югарыда әйтелгән җөмләләрнең кисәкләрен сызып ташлаганда, әнә шул положениега нигезләнеп эш иткән.

Алтынчы биттә татар һәм башкорт восстаниеләре искә алына, шуларның берсе – Алдар җитәкчелегендәге восстание. Тексттан соңгы астөшермәдә Алдар исеме нәкъ менә башкортларның әйдәп баручысы сыйфатында китерелә. Аннан соң цензор Алдарның 1704-1708 елларда рус гаскәрләренә каршы сугыш алып баруы турындагы җөмләне төшереп калдыра. Бу очракта сызып ташланган җөмлә сугыш бару фактын гына атый. Ә устав буенча тарихи әсәрләрдәге вакыйгаларны тасвирлауга карата авторның карашлары тыелмаган[23], әмма цензор В. Д. Смирнов сугыш даталарына ишарә итүне уставка каршы килү дип санаган, чөнки уставта цензура тарафыннан тикшерелә торган китапның рухына, авторның карашына, максатына зур игътибар бирү тиешлеге турында искәртелгән[24].

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Смирнов барлык рус булмаган халыкларны кабул итми, аларны русларга каршы куярга тырыша. Рус державасының куәтен шик астына алырлык бар нәрсәне дә, аныңча, кабул итәргә ярамый, шуңа күрә ул әлеге кулъязманың 7 нче битендә татарларга карата кулланылган *“олуг”* эпитетын сызып ташлаган.

Җиденче биттән башлап, цензор күләмле кыскартуларга керешә. Баштагы текстның мәгънәсе үзгәрү нәтиҗәсендә, автор (Р. Фәхреддинов) калган җөмләләрне үзе үк сызып ташларга мәҗбүр була. Устав буенча, цензорларга кызыл язу карасы белән генә төзәтмәләр кертергә рөхсәт ителә, димәк, кулъязмада карандаш белән кертелгән төзәтмәләр авторныкы. Мәсәлән, В. Смирнов франклар, гарәпләр һәм Синан паша, Физули, Кәмал Намык һ.б. данлыклы төрекләр турында искә алуларны кыскарта. Шуннан соң автор бөек рус галимнәре, шагыйрьләре, язучыларының исемнәрен сызып ташларга мәҗбүр була, чөнки алар төрекләр белән чагыштыру өчен генә китерелә. Автор югарыда әйтеп үтелгән төрек эшлеклеләренә кыскача сыйфатнамә бирелгән җөмләләрне дә алып ташлый[25].

Сигезенче биттә *“...Ләкин руслар вә госманлыларның ошбу кеби галимнәренә иткән мәхәббәтләре ни өчендер?!...”* дигән сорау белән башланып киткән абзац кызыклы. Шунда ук җавабы да бирелгән: чөнки бу кешеләр үз халкына, бигрәк тә, киләчәк буыннарга иҗат җимешләрен – хезмәтләрен һәм бөек фикерләрен калдырганнар. Смирнов *“госманлылар”* сүзен сызып ташлый, аның фикеренчә, күрәсең, руслар гына үз халкына фәнни хезмәтләр калдыра ала. Риза Фәхреддиновның татар әдәбиятына кагылышлы җитешсезлекләргә, мәктәпләрдә туган тел кагыйдәләре өйрәтелмәү һәм бөек кешеләрнең тәрҗемәи хәлләре язылмаган булуына борчылуы да бастырылырга рөхсәт ителми. Автор шулай ук, үз халкы өчен сөенә дә, көенә дә. Цензорның бу юлларны үткәрергә теләмәве татар халкын үз мәдәниятеннән аерырга омтылуы белән аңлатыла, күрәсең. Татар халкына ул һәрвакыт әдәбиятның кимчелекләре һәм туган телне өйрәнүнең кирәклеге турында искәртеп торырга теләми. Аныңча, мөселманнарның грамоталылыгы дәүләткүләм белем таратуда киртә булып тора, ул дини фанатиклык тудыра, бу исә рус халкыннан читләштерә[26].

Смирнов кереш өлешнең өченче бүлеген тулысы белән диярлек алып ташлый. Р. Фәхред-

динов татар тарихы буенча чыганакларның сакланмавына кайгыра. Аның фикеренчә, безнең тарих караңгылыкта кала бирә һәм галимнәр генә аннан чыгу юлын күрсәтә алалар. Р. Фәхреддинов төрле фәннәрне өйрәнергә, башка халыкларның фәнни хезмәтләрен кулланырга өнди. Ул үз җитешсезлекләрен һәм чорының ялгышлыкларын да яшерми, аларның киләчәк буыннар тарафыннан төзәтелергә мөмкин булуын истә тота. Риза Фәхреддинов, тарихның фән буларак мөһимлелеген аңлап, барлыкка килгән вазгыятьне үзгәртүгә һәм яхшыртуга бөтен көчен куя. Әмма ул цензура белән ярышта көчсез. Смирнов фикеренчә, өченче бүлек материаллары уставның төп маддәләренә каршы килә, ягъни алар катлаулар арасында яшерен нәфрәт кузгата, рус булмаган халыкларда үзаң уяту һич тә ярамый. Мөгаен, бу юлларны сызып ташлаганда, Смирновны шундый уйлар биләгән булгандыр. Үзалдына бердәнбер - монархия, чиркәү һәм державаның торыклылыгын саклау максаты куеп, төрек филологиясе профессоры үз амбицияләрен матбугат һәм цензура турындагы устав артына яшерә. Ул үзенең чиновник бурычын үти: халыкка царизмга ошамый торган фикер һәм кәефләр үтеп керүдән саклый.

“Асар”ның кереш өлешеннән алып ташланган урыннарын мисал итеп китерик.

“Гарәпләр, франклар бер тарафта торсын. Бу маддәдә госманилар илә русларны бер фикер идәлем. Мәсәлән, Ломоносов, Державин, Фонвизин, Карамзин, Жуковский, Крылов, Александр Пушкин, Грибоедов, Лермонтов, Гоголь, Гончаров, Тургенев, Лев Толстой кеби әдипләр вардыр. Ушандак[27] госманиларда Синан паша[28], Физули[29], Кучи бәк[30], Нәдим[31], Кани[32], Гасыйм (Әүкыйанус сахибе) [33], Гакиф паша[34], Рәшид паша[35], Фуад паша[36], Пертев паша[37], Шинаси[38], Зыя паша[39], Сәгыйдулла паша[40], Кәмал Намык[41], Сами бәк[42], Әхмәд Мидхәт[43], Әбуз-Зыя Тәүфыйк[44] кеби фазыйльләр[45] вардыр. Бунларны исә дәгел мөгаллимнәр вә олуг галимнәр, бәлки мәктәпкә йөргән һәр балалары исемнәрене белеп, мәхәббәт идәр, вә һәрберене хөрмәтле зат игътикад[46] итеп, мөмкин кадәр сүзләрене өйрәнер, шигырьләрне ядына алыр, ахырында тәрҗемәлеренә вә дөньяда ни рәвештә тордыкларына кадәр, бер калдырмый әшнә улыр. Бунларны сөяр вә бунлар васитасы[47] илә бөтен милләтенә ихлас баглар. Бундан исә, дустлык вә иттихад[48] пәйда улыр.

Ләкин руслар вә госманиларның, ошбу кеби галимнәренә иткән мәхәббәтләре ни өчендер?!... Буның җавабы исә бик йиңел улып, мәзкүр[49] затларның үзләренең кавемнәре вә, хосусан, киләчәк балалары өчен газиз әсәрләр, хосусан, гали фикерләр, ядкяр итдекләреннәндер.

Безләрдә исә та[50] бу көнемезгә кадәр, әдәбият фәүкыль-гадә[51] нәкыйстер[52]. Үз лисанымызның кагыйдәсе мәктәпләремездә дәрес ителенеп укылмадыгы кеби, истигъмаль[53] һәм ителмәктәдер. Үземезгә нисбәт илә фозала[54] гадь иделмеш[55] кемсәләремезнең тәрҗемәләре язылмай, тәннәре илә бергә каберләргә күмелмәктәдер. Буның өчен дә милләтемез, фәкать бер күләгә кабиленнән истихкямсездер[56]. Хәлбуки, дөньяның иң күп сүзле кавемнәре вә иң дәгъвалы халыклары безләрмез. Мәҗлесләрдә сөйләшкән сафсаталарымыз дөньяларны тутырыр иде, буңа исә тәәссеф[57] итмәк мөмкин дәгелдер.

**3**

Үткән бәхәсләремездә тәфсыйль[58] ителгән рәвешчә, безләр, күземезне ачып әтрафымызга бакдыкымызда үземезнең бабаларымыз вә әсляфләремез[59] дия игътикад итмеш галимнәремез хәлләрене тәмам бер караңгылык сахрасында күрергә мәҗбүр улмактамыз. Бунлардан ля әкальле[60] Казан ханлыгы бетдеке заманалардан соң улганнарыннан улса да, безләргә әсәрләр калмадыгы яки калып та безләргә килеп йитешмәдеке тәәссеф ителенәчәк хәлләрдәндер. Чөнки мөкаддәм заман голямасы тарафыннан бер хәдисә вә яки бер тәрҗемәнең дөрест язылып калынмагы, киләчәкләр өчен кыйммәтсез бер һәдия[61] хисап иделенәчәгендә шөбһә улмаз.

Имди, бәян итдекемез караңгылык шул хәленчә торсын һәм дә киләчәк заманаларның эченә кереп тугры сузылып китсенме? Юкса, һәр гасырның голямасы, үзләренең тәкатьләре йиткән кадәр мәгълүмат җыеп, хәләфләргә[62], әз улса да, ядкяр итеп калдырсыннармы?!.. Буның җавабы исә тәкъвалык сатучыларга, рәддия[63] язучыларга, әһле ислам арасына юк сүзләр илә ифтирак[64] салучыларга дәгел, бәлки хөсне холык сахибе фазыйльләргә хәвалә[65] ителенмәктәдер. Анлар исә, мәсьәләне әтрафлы мөзакәрә[66] итеп, нәтиҗәсене белерләр.

Ләкин безнең гаҗиз фикеремезгә күрә, асарлары илә дөнья тулган кавемнәр, китаплары хисапсыз улган фәннәр хакында һәмишә[67] ислах[68] вә тәгъмир[69] иҗтиһадында улмак вә, мөмкин

кадәр, хәләфләргә тәрбияләп калдырмак тиешледер. Эш бөйлә улдыгында дөнья тулысы дәгел мөкәммәл[70], бер әсәрләре улмаган кавемемез тарихыны вә галимнәренә хас улган әхвальләрене тәфтиш итмәктән тукталып тормакымыз дөрест улмаз. “Безгә бабаларымыз бер әсәр дә калдырмады, шуның өчен без дә сезгә калдырмадык” димәкемез мөнасиб[71] улмаз. Аның өчен бабаларымыздан әсәрләр калмадыгына бәлки бәгъзе бер сәбәпләр улына белер, әмма безнең өчен гозер[72] улмаз, улса, кабул ителмәз. Бабаларымыздан файдалы әфкярләр[73] калмадыгының ачы йимешләрен ашарга безләр мәҗбүр улдык. Әгәр дә балаларымызга һәм бу кеби мөгамәләдә улынсак, вай безнең хәлемезгә!...

Кавемемез вә сәләфләремезнең хәлләрене белергә безләр ни кадәр мөштак[74] улыр исәк, бәлки безнең хәлләремезне белер өчен хәләфләремез бездән зиядә[75] хәрис[76] тә улырлар. Киләчәк зөррияләремез[77], бәлки җөмлә[78] хәрәкат[79] вә сәкәнатымызны[80] мизанга салып тартырлар.

*Бу маддәдә, камил сәрмаямез[81] юк димәк гозер дәгелдер. Аның өчен, камил сәрмая улынмадыгыннан накыйсьләрне үземез илә кабергә алып китүемез дә җаиз[82] улмаз. Бәлки азмыкүпме, хәзинәдә варны гарыз[83] итмәк тиешледер. Дөнья үзе, бер дәкыйкадә[84] яратылып тәмам улмадыгы кеби, дөньяда улган нәрсәләр дә, дәфгатән[85] кәмаләт тапмаз. Бәлки аз вә акрынлык үзәрендә кәмаләт тәхсил[86] ителенер. Бер кемсәнәнең noксаныны[87] икенче берсе икмаль[88] итә. Бер заман әһеленең хатасыны икенче бер заман әһеле тасхих[89] кылыр”.*

Әмма бу сүзләр үз адресатына – халыкка барып җитми. Беренчедән, патша Россиясе мәгърифәтле, өстәвенә, бай тарихлы һәм югары рухи культуралы рус булмаган халыклардан читләшә. Икенчедән, дәүләттә һәрвакыт Смирнов кебек, үз мәсләкләренә туры китереп, рус булмаган халыкларның үсешен тоткарларга омтылучы һәм амбицияләрен дәүләтнең үзләренә тулы ирек бирүче устав һәм законнары артына яшерүче чиновниклар булган.

**Искәрмәләр:**


1. Харисов А. И. Коллекция рукописей Р. Фахретдинова в Научном архиве Башкирского филиала АН СССР // Южноуральский археографический сборник.-Уфа,1973.-Вып.1.-С.270.
2. Госманов М. Яңа табылган әдәби, тарихи истәлекләр // Казан утлары.-1966.-№7.-Б.118-120.
3. Харисов А. И. Указ.соч.-С.270-273; Хәйруллин Ә. Галимнең кулъязма мирасы // Казан утлары. - 1984. - №1. - Б.157 - 164; Хайруллин А. Н. Рукописное наследие Р. Фахрутдинова как источник изучения истории татарской общественной мысли // Проблема преемственности в татарской общественной мысли.-Казань,1985.-С.73-84.
4. Шараф А. Воспоминания об отце // Ризаэтдин Фахретдин: фәнни-биографик җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов. Научно-биографический сборник.-Казань,1999.-С.119.
5. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. Беренче җөзьэ.-Оренбург,1907.-Б.2-4.
6. Утябай-Карими Р. Слово в защиту религии // Идель.-1991.-№8/9.-С.95.
7. Каримуллин А. Г. Татарская книга начала XX века.-Казань,1974.-С.11.
8. Каримуллин А. Г. Татарская книга пореформенной России.-Казань,1983.-С.110.
9. Гордлевский В. А. Памяти В. Д. Смирнова // Избр. соч.-М.,1968.-Т.4.-С.413.
10. Там же.-С.408.
11. Каримуллин А. Г. Татарская книга пореформенной России…-С.132.
12. Каримуллин А. Г. Татарская книга начала XX века…-С.188.
13. Госманов М. Гаяз Исхакый: “Ике йөз елдан соң инкыйраз” һәм патша цензурасы // Казан утлары.-1995.-№10.-Б.152-181.
14. Усманов М. А. Наследие Ризы Фахретдинова // Советская Татария.-1989.-14 февр.
15. Фәхреддин Р. Асар. Беренче жөзьэ.-1899.-32 б. (Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе. Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең Шәрек секторы. “1496-т” шифрлы кулъязма).
16. Фәтхи А. Ризаэтдин Фәхретдин // Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары. Беренче бүлек.-Казан,1960.-5 чыг.-Б.39-43.
17. Татар әсәрләренең цензурасы 1874 елда С.-Петербургның цензура комитетына күчерелгән. Кара: Каримуллин А. Г. Татарская книга пореформенной России…-С.101.
18. хәмиять - саклау.

19. мәгъруф - танылган.
20. тәгъриф итү — таныту.
21. Фәхреддин Р. Асар. Беренче җөзьэ.-Казан,1900.-Б.5.
22. Устав о цензуре и печати // Мсерианц Р. Законы о печати.-М.,1899.-С.65.
23. Там же.-С.67.
24. Там же.-С.67.
25. ОРРК НБ КГУ. Ед.хр. 1496-т. С.7.
26. Гордлевский В. А. Указ. соч.-С.413.
27. ушандак - шулай ук.
28. Синан паша (1440-1486) - мәшһүр төрек прозаигы, галим һәм шагыйрь. Проза әсәрләрендәге темалары дин, мистика, әхлак, гаилә. Гарәп һәм төрек телләрендә язган (Islam ansiklopedisi.-Cild 10.-Istanbul,1966.-S.666-670).
29. Физули (1498-1556) - Кербел шәһәрендә туган. Зур лирик әдип һәм галим. Шигъри әсәрләрен фарсы, гарәп һәм азәрбәйҗан телләрендә язган. Иҗатының югары дәрәҗәсе – “Ләйлә–Мәҗнүн” темасы. (Большая советская энциклопедия, 2-ое изд.-М.,1956.-Т.45.-С.81-82).
30. Кучи бәк (?-1650) - госманлы дәүләтенең сәяси эшлеклесе. Госманлы дәүләтенең торышы һәм таркалу сәбәпләре турында язылган мөһим һәм фактик материалларга бай сәяси, икътисади трактатлар авторы (Советская историческая энциклопедия.-М.,1965.-Т.7.-Стб.1020).
31. Нәдим Әхмәд (?-1730) - төрек шагыйре, ләззәтләнү фәлсәфәсенә өнди. Шигъриятендә гади тел белән язарга омтылган (БСЭ.-М.,1954.-Т.29.-С.359).
32. Кани Мөхәммәд Рафыйк (1885-?) - әфган язучысы, филолог һәм фольклорчы. “Ике гашыйк туган” дип исемләнгән мораль-этик эчтәлекле, көнкүреш мәсьәләләрен чагылдыра торган беренче әфган повестеның авторы (Краткая литературная энциклопедия.-М.,1966.-Т.3.-С.363).
33. Гасыйм әфәнде (1755-1820) - тел белгече, тарихчы һәм шагыйрь. Газиантепода туган. “Әүкыйанус” – Фирузабади сүзлегенең гарәпчәдән тәрҗемәсе (Türk ansiklopedisi.-Cilt 3.-Istanbul.-С.448).
34. Гакиф паша (1787-1845) - төрек язучысы һәм сәяси эшлекле. Мәхмүд II чорында тышкы эшләр министры. Газәл, касыйдә, мәрсияләр язган. Төрек әдәбияты үсешендә сизелерлек роль уйнаган (КЛЭ.-М.,1962.-Т.1.-С.118).
35. Рәшид паша (1799-1858) - төрек дәүләт эшлеклесе һәм дипломат. Бөек вәзир, тышкы эшләр министры, Англия һәм Франция илче. Төркиядәге яңа әдәби мәктәпкә нигез салучы (БСЭ.-М.,1955.-Т.36.-С.458).
36. Фуад паша Мөхәммәд (1814-1914) - төрек дәүләт эшлеклесе, шагыйрь, госманлы теле грамматикасын төзүче. (Энциклопедический словарь. Гранат.-М.,1927.-Т.45.-Ч.1.-Стлб.72-73).
37. Пертев паша, Мөхәммәд Сәед (1785-1837) - госманлы тышкы эшләр министры һәм шагыйрь. (Islam...-Cilt 9.-1964.-S.554).
38. Шинаси Ибраһим (1826-1871) - төрек язучысы, публицист. Яңа төрки әдәбиятның нигез салучысы. Тәнзимат чорының күренекле вәкиле. Төрки әдәбиятында беренче драма әсәре – “Шагыйрьнең өйләнүе” комедиясе басылу Шинаси исеме белән бәйле. Төрек мәкаль һәм әйтемнәренең беренче җыентыгы авторы (КЛЭ.-М.,1975.-Т.8-С.722).
39. Зыя паша (1825-1881) - төрек шагыйре, публицист. Тәнзимат чорының күренекле вәкиле. Төрек әдәбиятын европалаштыруны пропагандалаучы, аны халыкка якынайтырга өнди, телне демократлаштыру өчен көрәшә (КЛЭ.-М.,1962.-Т.2.-С.123).
40. Сәгыйдулла паша (1830-1914) - бөек вәзир, госманлы дәүләт эшлеклесе. Газета мөхәррире. (Islam...-Cilt 10.-S.82-86).
41. Кәмал Намык (1840-1888) - төрек язучысы, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Тәнзимат чорының зур вәкиле. Төрек әдәбиятының формалашу һәм үсешенә булышлык итүче, мәгърифәт өчен, төрек телен яңарту өчен көрәшкән. Төрек романына нигез салучы (КЛЭ.-М.,1968.-Т.5.-С.95).
42. Сами бәк Шәмседдин (1850-1904) - төрек язучысы, лексикограф, сүзлекләр төзүче (БСЭ.-3-е изд.-М.,1978.-Т.29.-С.379).
43. Әхмәд Мидхәт (1844-1913) - төрек язучысы, мәгърифәтче. Төрек әдәбиятында кыска хикәя һәм романга нигез салучы. Сиксән әсәр авторы (КЛЭ.-М.,1962.-Т.1.-С.371).
44. Әбуз-Зыя Тәүфик - үз иҗатында хис һәм ирекле шәхесне яклаучы, искергән, деспот-

лыкка нигезләнгән феодаль мөселман традицияләренә каршы көрәшкән, көчләп өйләндерү системасын тәнкыйтьләгән (Алькаева Л. О. Творчество Халида Зии Ушаклыгиля.-М.,1965.-С.10).

45. фазыйль - галим кешегә карата кулланыла торган эпитет
46. игътикад - ышану, инану
47. васита - арадашлык
48. иттихад - фикер бердәмлеге, берләшү
49. мәзкүр - югарыда күрсәтелгән
50. та - хәтле, чаклы, кадәр
51. фәүкыль-гадә - гадәттән тыш
52. накыйс - тәмам түгел
53. истигъмаль - куллану
54. фозала - фазыйльнең күплек саны
55. ... гадь иделмеш - ... дип саналган
56. истихкям - чыдам
57. тәәссеф - ачыну, үкенеч
58. тәфсыйль - аңлатып сөйләп бирү
59. әсляф - борынгы кешеләр
60. ля әкальле - һич булмаса
61. һәдия - бүләк
62. хәләф - киләчәк буын
63. рәддия - кире кагу, дөрес түгеллеген күрсәтү
64. ифтирак - аерылу
65. хәвалә - тапшыру, йөкләү
66. мөзакәрә - фикер алышу
67. һәмишә - өзлексез
68. ислах - үзгәртү, яхшыландыру
69. тәгъмир - төзәтү, яңарту
70. мөкәммәл - камилләшкән
71. мөнасиб - яраклы, муафыйк
72. гозер - сылтау, сәбәп
73. әфкяр - фикерләр
74. мөштак - омтылучы
75. зиядә - артык
76. хәрис - ач күзле, комагай
77. зөррия - буын
78. җөмлә - барлык
79. хәрәкат - эшчәнлек
80. сәкәнат - тик тору
81. сәрмая - бәя
82. җаиз - дөрес, кирәк
83. гарыз - тәкъдим итү
84. дәкыйка - минут
85. дәфгатән - кинәт
86. тәхсил - хасил итү
87. ноксан - хаталар
88. икмаль - төзәтү
89. тасхих - дөресләү.